**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында
2024 елда үзара салым кертү турында

**2023 елның 16 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Карашай-Саклау авыл җирлегенең Чураш  авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, мобилизацияләнгәннәрнең гаилә әгъзалары ,яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән  600 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Чураш авылынлагы  урамнарны яктырту җайланмасы (урам яктырткычларын сатып алу һәм урнаштыру);
2. Чураш торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү максатында су өчен савытлар сатып алу ;
3. Юлларны кардан чистарту, җәйге вакытта территорияне урап узу, Чураш  торак пункты зиратына керү юлын ремонтлау  (килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары, запас часть)
4. Чураш торак пункты паркының коймасын тоту

3. Әлеге карарны Карашай-Саклау  авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Карашай-Саклау  авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче В.В.Хосниева